Бердәмлектә көч

Бакча коллективының бурычы – ата-аналар белән берлектә һәр баланы бәхетле итү. Ә бәхет төшенчәсе күпкырлы. Ул кешенең үз сәләтен ача белүендә дә, дөньяның матурлыгы белән хозурлануында да, матурлык тудыруында катнашуында да, кешеләрне һәм үзен яратуында да чагылыш таба. Фәкать ата-аналар ярдәмендә, күмәк көч белән генә мөгаллимнәр балаларга чын бәхетне бирә ала.

Балалар бакчасы тәрбиячесе – ул ата-аналар белән арадашчы да, оештыручы, балаларны яклаучы, аларның ихтыяжларын өйрәнеп, тормышта үз урыннарын табарга юнәлеш бирүче дә.

Рухи-әхлакый тәрбия бирүдә балаларны аралашырга өйрәтү дә аеруча мөһим. Шул максаттан, без үзебезгә «Балалар өчен ижатка, танып-белергә, ачышларга, аралашырга юл ачыйк!» дигән сүзләрне девиз итеп алдык. Иң әһәмиятлесе шул: бала үз-үзенә, үз мөмкинлекләренә ышанырга, тумыштан бирелгән сәләтен үстерергә омтылырга тиеш.

Бакчада уздырылган төрле чараларда әти-әниләр актив катнаша. Мәсәлән :”Исәнме алтын көз”,”Юлларда сак бул”,”Әниемнең алтын куллары” диеп исемләнгән күргәзмәләр оештырдык. Тематик рәсемнәр һәм кул эшләре күргәзмәсе, шигырь бәйгеләре әти-әниләрдә зур кызыксыну тудырды. Без бу бәйгеләргә нәтиҗә ясап әти-әниләргә рәхмәт хатлары, балаларга мактау кәгазьләре тапшырабыз.

Тәрбиянең төп асылы –балалар бакчасы белән гаиләнең бердәмлегендә. Гаиләләр белән даими хезмәттәшлек итеп, һәр гаилә белән ярдәмләшеп эшләгәндә уңай нәтиҗәләргә ирешергә була.

Күгәрчен авылы “Каенкай” балалар бакчасы тәрбияче: Мукриева Гөлүсә Хөсәен кызы

Юлларда сак бул!
УГОЛОК
ПО ОХРАНЕ ТРУДА
28 апреля
ДЕТИ
СТОЙ
ИДИ
01